СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

22.10.2018 с. Верхний Услон № 37-412

**“Югары Ослан муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру " максатчан программасын тормышка ашыру барышы турында**

Югары Ослан муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссия рәисе Л. С. Хәкимҗановның «Югары Ослан муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру «максатчан программасын гамәлгә ашыруның барышы» турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң,

**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**карар чыгарды:**

1. "Югары Ослан муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру" максатчан программасын тормышка ашыру барышы турында” мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетына юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтүгә, балалар юл-транспорт җәрәхәтләнүләрен профилактикалауга, юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерүгә, транспорт чаралары хәрәкәте шартларын камилләштерүгә һәм җәяүлеләрнең иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар уздыруны дәвам итәргә.

3. Тәкъдим итергә:

- авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына компетенцияләре кысаларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә, шулай ук юлларны тиешле хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» ЮХИДИ бүлегенә Югары Ослан муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча актив эшне дәвам итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль район Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль**
**районы Башлыгы** **М.Г. Зиатдинов**